| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» 04 2023 ел № 147

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Социаль, икътисади, экологик һәм башка факторлар җыелмасыннан чыгып, авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, әлеге территориянең уңайлы яшәү шартлары белән комплексы тотрыклы үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү максатларында; гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясының 2 өлешенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 3-4 өлешенә туры китереп, Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов